**Совет Большеачасырского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл жирлеге Советы**

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2 ноябрь 2020 ел

№13

Аерым муниципаль норматив хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану турында

Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегендә норматив хокукый актлар системасын актуальләштерү максатыннан Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карарларын үз көчен югалткан дип танырга:
- 2014 елның 11 мартындагы 174 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»;
- 2018 елның 23 ноябрендәге 186 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2014 елның 11 мартындагы 174 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»;
- 2018 елның 17 декабрендәге 188 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында».

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**